ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06 февраль, 2015 ел г.Казань № 17

**Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максаты белән мөрәҗәгать итү очраклары турында эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиленә белдерү тәртибе хакында**

2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” №273-ФЗ Федераль законның 9 статьясының 5 өлеше нигезендә **боерык бирәм:**

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максаты белән мөрәҗәгать итү очраклары турында эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиленә белдерү тәртибен расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Рәис С.Е.Иванов

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 06.02.2015 ел,
№17 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты
дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү
максаты белән мөрәҗәгать итү очраклары турында эшкә яллаучы
(эш бирүче) вәкиленә белдерү тәртибе

1. Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максаты белән мөрәҗәгать итү очраклары турында эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиленә белдерү (алга таба – белдерү) Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәткәре (алга таба – дәүләт хезмәткәре) тарафыннан әлеге Тәртипкә карата №1 кушымтада күрсәтелгән рәвештә язмача, аны эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиленең Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында коррупциячел һәм башка хокук бозуларны кисәтү эшендә җаваплы булган вәкаләтлесенә (алга таба – вәкаләтле зат) тапшыру, яки мондый белдерүнамәне почта аша җибәреп, гамәлгә ашырыла.

2. Дәүләт хезмәткәре аны коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максаты белән нинди дә булса затларның аңа мөрәҗәгать итүнең барлык очраклары турында да, дәүләт хезмәткәренә аны коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максаты белән мөрәҗәгать иткән көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча, эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиленә белдерергә бурычлы.

Дәүләт хезмәткәре командировкада, отпуск ялында, хезмәт үтми торган җирдә булган очракта, ул хезмәт итү урынына килеп җиткәч, кичекмәстән, эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итәргә бурычлы.

3. Белдерүнамәдә чагылдырылучы мәгълүматлар исемлеге үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

– белдерүнамә җибәргән дәүләт хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазифасы, яшәү урыны һәм телефоны;

– аның хезмәт вазифаларын үтәвенә бәйле рәвештә, аны коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максаты белән, дәүләт хезмәткәренә нинди дә булса затларның мөрәҗәгать итү очрагы ачыкланган шартларны тасвирлау (датасы, урыны, вакыты, башка шартлар). Әлеге Тәртипнең 10 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәткәре белдерүнамә җибәргән очракта, коррупциячел хокук бозуларны кылуга җәлеп ителүче дәүләт хезмәткәренең фамилиясе, исеме,

атасының исеме һәм вазифасы күрсәтелә;

– мөрәҗәгать итүче затларның гозере буенча дәүләт хезмәткәре кылырга тиеш булган коррупциячел хокук бозулар хакында төгәлрәк мәгълүматлар;

– дәүләт хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуга җәлеп итүче физик (юридик) зат турында барлык билгеле булган мәгълүматлар (фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазифасы һ.б.);

– дәүләт хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуга җәлеп итү юллары (сатып алу, янау, вәгъдә бирү, алдау, көчләү, куркыту һ.б.);

– дәүләт хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуга җәлеп итү шартлары (телефоннан сөйләшү, шәхсән очрашу, почта аша җибәрү һ.б.), шулай ук коррупциячел хокук бозуны кылу турында зат тәкъдименнән баш тарту (кабул итү) турында мәгълүмат;

– дәүләт хезмәткәре тарафыннан белдерүнамәне тутыру датасы;

– белдерүнамә тутырган дәүләт хезмәткәренең имзасы.

4. Белдерүнамәләр әлеге Тәртипкә карата № 2 кушымтада китерелүче рәвештә төзелгән Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максаты белән мөрәҗәгать итү очраклары турында белдерүнамәләрне теркәү журналында (алга таба – теркәү журналы) ирешкән көнендә мәҗбүри теркәлергә тиеш, ул беркетеп куелырга һәм номерланырга, шулай ук Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты мөһере белән таныкланырга тиеш.

Теркәү журналын алып бару вәкаләтле затка йөкләнә.

5. Белдерүнамәне кабул итеп алган вәкаләтле зат, аны теркәү журналына теркәгәннән соң, белдерүнамә җиткергән дәүләт хезмәткәренә имзалатып, белдерүнамәне кабул иткән зат турындагы белешмәләрне, кабул итүнең көнен һәм вакытын күрсәтеп, белдерүнамә талоны бирә.

Белдерүнамә талоны ике өлештән тора: белдерүнамә талоны төпсәсе һәм белдерүнамә талоны (әлеге Тәртипкә карата № 3 кушымта).

Тутырганнан соң белдерүнамә талонының төпсәсе вәкаләтле затта кала.

Белдерүнамә почта аша ирешкәндә, белдерүнамә талоны белдерүнамә җибәрүче дәүләт хезмәткәренә почта аша заказлы хат итеп җибәрелә.

Белдерүнамәне теркәүдән баш тарту, шулай ук белдерүнамә талоны бирмәү рөхсәт ителми.

6. Белдерүнамә теркәү журналында теркәлгәннән соң, ул андагы мәгълүматларны алга таба тикшерүне оештыру максаты белән Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисенә (яки аны алмаштыручы затка) карап тикшерү өчен тапшырыла.

7. Алынган белешмәләрнең кагылгысызлыгы вәкаләтле зат тарафыннан тәэмин ителә.

8. Аның хезмәт вазифаларын үтәвенә бәйле рәвештә, аны коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максаты белән, дәүләт хезмәткәренә нинди дә булса затларның мөрәҗәгать итү очраклары турында яки нинди дә булса затларның башка дәүләт хезмәткәрләренә аларны коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максаты белән мөрәҗәгать итүенең ачыкланган очраклары турында мәгълүматларны тикшерүне оештыру Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе (яки аны алмаштыручы зат) кушуы буенча, белдерүнамәләрне Татарстан Республикасы Прокуратурасына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Татарстан Республикасы буенча Федераль иминлек хезмәте идарәсенә җибәрү, белдерүнамәне җиткергән дәүләт хезмәткәре, дәүләт хезмәткәреннән җиткерелгән белдерүнамәдә күрсәтелгән зат белән әңгәмә кору, дәүләт хезмәткәреннән белдерүнамәдә бәян ителгән мәгълүматларга карата аңлатмалар алу юлы белән вәкаләтле зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

9. Белдерүнамә вәкаләтле зат тарафыннан аны теркәү журналында теркәгән көннән алып 10 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Прокуратурасына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Татарстан Республикасы буенча Федераль иминлек хезмәте идарәсенә җибәрелә.

10. Хезмәт вазифаларын башкаруга бәйле рәвештә, аларны коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максаты белән, нинди дә булса затларның башка дәүләт хезмәткәрләренә мөрәҗәгать итү очраклары турында билгеле булган дәүләт хезмәткәре бу хакта эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиленә Тәртиптә билгеләнгән аналогик рәвештә хәбәр итәргә хокуклы.

11. Дәүләт хезмәткәренең 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” №273-ФЗ Федераль законның 9 статьясының 1 өлешендә каралган вазифаи (хезмәт) бурычларын үтәмәве аны дәүләт хезмәтеннән куу яисә аны Россия Федерациясе законнары нигезендә башка төрле җаваплылыкка тарту өчен сәбәп булырдай хокук бозу булып санала.

06.02.2015 ел, №17 Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максаты белән мөрәҗәгать итү очраклары турында эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиленә белдерү тәртибенә карата
№1 кушымта

______________________________
(эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиленең Ф.И.А., вазифасы)

______________________________
(дәүләт органы исеме)

кемнән______________________________
(дәүләт граждан хезмәткәренең Ф.И.А., вазифасы, яшәгән урыны, телефоны)

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максаты белән мөрәҗәгать итү очраклары турында
БЕЛДЕРҮНАМӘ

Түбәндәгеләр хакында хәбәр итәм:

1. ______________________________
(аның хезмәт вазифаларын үтәвенә бәйле рәвештә, аны коррупциячел хокук бозуларга җәлеп итү
______________________________
максаты белән, дәүләт гражданлык хезмәткәренә нинди дә булса затларның
______________________________
мөрәҗәгать итү очраклары билгеле булган шартларны тасвирлау)

2. ______________________________
(мөрәҗәгать итүче затларның гозере буенча дәүләт гражданлык хезмәткәре кылырга тиеш булган
______________________________
коррупциячел хокук бозу очрагы турында төгәлрәк мәгълүмат)

3. ______________________________
(дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуны кылуга җәлеп итүче
______________________________
физик (юридик) зат турында билгеле булган барлык мәгълүматлар)

4. ______________________________
(дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуны кылуга җәлеп итү ысулы һәм шартлары,
______________________________
шулай ук коррупциячел хокук бозу турында затның тәкъдимен кабул итүдән баш тарту
______________________________
(кабул итү) турында мәгълүмат)

| ______________ | ______________ | ______________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (имза) | (инициаллар һәм фамилия) |

06.02.2015 ел, №17 Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максаты белән мөрәҗәгать итү очраклары турында эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиленә белдерү тәртибенә карата
№ 2 кушымта

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максаты белән мөрәҗәгать итү очраклары турында белдерүнамәләр

ТЕРКӘҮ ЖУРНАЛЫ

<table>
<tr><th rowspan="2">№ п/п</th><th rowspan="2">Белдерүнамәнең номеры, датасы (белдерү талонының номеры һәм датасы күрсәтелә)</th><th colspan="4">Белдерүнамә җибәргән дәүләт гражданлык хезмәткәре турында мәгълүматлар</th><th rowspan="2">Белдерүнамәнең кыскача эчтәлеге</th><th rowspan="2">Белдерүнамәне кабул итеп алган затның Ф.И.А.</th></tr>
<tr><th>Ф.И.А.</th><th>Шәхесне таныклый торган документ – Россия Федерациясе гражданы паспорты; хезмәт таныклыгы</th><th>Вазифа</th><th>Элемтә өчен телефон номеры</th></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
</table>

06.02.2015 ел, №17 Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максаты белән мөрәҗәгать итү очраклары турында эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиленә белдерү тәртибенә карата №3 кушымта

| ТАЛОН-ТӨПСӘ | БЕЛДЕРҮНАМӘ ТАЛОНЫ |
|---|---|
| № __________ | № ___________ |
| Белдерүнамә түбәндәгедән кабул ителде:<br>__________________________________________<br>__________________________________________<br>(дәүләт гражданлык хезмәткәренең Ф.И.А.) | Белдерүнамә түбәндәгедән кабул ителде:<br>__________________________________________<br>__________________________________________<br>(дәүләт гражданлык хезмәткәренең Ф.И.А.) |
| Белдерүнамәнең кыскача эчтәлеге:__________<br>__________________________________________<br>__________________________________________<br>__________________________________________<br>__________________________________________<br>__________________________________________ | Белдерүнамәнең кыскача эчтәлеге:__________<br>__________________________________________<br>__________________________________________<br>__________________________________________<br>__________________________________________<br>__________________________________________ |
| __________________________________________<br>__________________________________________<br>(белдерүнамәне кабул иткән затның имзасы һәм вазифасы) | Белдерүнамәне кабул итте:<br>__________________________________________<br>(белдерүнамәне кабул иткән затның Ф.И.А., вазифасы)<br>__________________________________________<br>(журнал буенча номеры) |
| «___» _____________20 __ ел. | «___» _____________20 __ ел. |
| __________________________________________<br>(белдерүнамә талоны алган затның имзасы)<br>«___» _____________20 _ ел. | __________________________________________<br>(белдерүнамәне кабул итеп алган дәүләт гражданлык хезмәткәренең имзасы) |

__________________________________________